СОВЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Нижнее Чекурское

21 июнь 2024 ел № 43/2

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип танылa:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 18.08.2023 № 33/2 карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Түбән Чәке
авыл җирлеге башлыгы А.В.Солдатов